Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Казысы авыл җирлеге Советының өченче утырышы

Татар Казысы авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

24 ноябрь, 2025 ел № 9

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пунктлар территориясендә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 8 ноябрендәге 129 номерлы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Татар Казысы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пунктлар территориясе өлешендә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 8 ноябрендәге 129 номерлы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге советы карарына (Татар Казысы авыл җирлегенең 2021 елның 14 декабрендәге 33 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар преамбуласында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә»

кушымтасы преамбуласында «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы белән» сүзләренә алмаштырырга.

1.3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлегенең торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә 2, 2.1, 3, 4, 5 нче кушымталарда «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 ст., 56 статьяларында» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татар Казысы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Татар Казысы авыл җирлеге башлыгы — Ф.Г.Кәримуллин